Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № XXX-2**

Балык Бистәсе штп. 2022 елның 30 декабрендә

Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә шартнамәләр төзү хокукына ачык аукцион әзерләү һәм уздыру тәртибе турындагы Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2020 елның 5 июнендәге LIII-4 номерлы карары белән расланган Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә шартнамәләр төзү хокукына торглар әзерләү һәм уздыру максатларында, "Реклама турында" 2006 елның 13 мартындагы 38-ФЗ номерлы, "Профессиональ керемгә салым" махсус салым режимын билгеләү буенча эксперимент уздыру турында" 2018 елның 27 ноябрендәге 422-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә, “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә шартнамәләр төзү хокукына ачык аукцион әзерләү һәм уздыру тәртибе турындагы Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2020 елның 5 июнендәге LIII-4 номерлы карары белән расланган Нигезләмәгә (алга таба – Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 Нигезләмәнең 2.1 пунктындагы 6 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“мөрәҗәгать итүче – аукцион уздыруның электрон мәйданчыгында теркәлгән һәм тәкъдим ителгән шартларда аукционда катнашу өчен гариза биргән юридик яисә физик зат, индивидуаль эшкуар яисә һөнәри керемгә салым түләүче (үзмәшгуль)”;

1.2 Нигезләмәнең 2.1 пунктындагы 7 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“аукционда катнашучы – аукционда катнашуга кертелгән юридик яисә физик зат, индивидуаль эшкуар яисә һөнәри керемгә салым түләүче (үзмәшгуль);”.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны транспорт, төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы

Р.Р. Ислямов